**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**"26" сентябрь 2018 ел** **№ 85**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү һәм үткәрү турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Кама Тамагы районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставының 15 статьясы нигезендә, Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге башлыгының 2018 елның 22 сентябрендәге 06 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары, Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советының 2018 елның 22 сентябрендәге 84 номерлы «Җирле референдум үткәрү инициативасы турында» карары нигезендә Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы **карар итте**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча 2018 елның 18 ноябренә җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:
"Сез 2019 елда Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 500 сум үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча билгеләнгән эшләрне не хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме:
*** Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру:**
- торак пунктлар эчендә чүп үләннәре чабу (җәйге-көзге чор) ;
- мемориаль такта (һәйкәл) төзү һәм Каратал авылында Бөек Ватан сугышында һәлак булган сугышчыларга салынган һәйкәл коймаларын алыштыру .
*** - җирлек торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**

- вак таш түшәлгән юлны ремонтлау;
- көзге-кышкы чорда юлларны карап тоту.
*** Күмү урыннарын карап тору:**
- зиратларны чүп үләннәреннән чистарту, триммер сатып алу;
- инвентарь саклау өчен корылма төзелешен тәмамлау;
- Атабай авылында контейнер мәйданчыклары өчен урыннар белән зират коймаларын алмаштыру (дәвам итү).
*** җирлекнең торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:**
-янгын гидрантларын (җайланмаларны) язгы-җәйге чорга һәм кышка әзерләү (шул исәптән кардан чистарту),аларга яктылык кайтаручы билгеләр урнаштыру.
*** Каты көнкүреш калдыкларын җыю һәм ташу эшчәнлеген оештыру**
- каты көнкүреш калдыклары полигоннарын карап тоту һәм чистарту (шул исәптән чүп җыю һәм чыгару).
*** Халыкны су белән тәэмин итүне оештыру**:
- су белән тәэмин итү системасын ремонтлау ( шул исәптән чыгым материалларын сатып алу));
- Каратал авылында скважина һәм су башнясын норматив хәлгә китерү (шул исәптән санитар зонаны төзекләндерү, коймалар урнаштыру).”

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:
1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;
2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Караталга авылы, Күпер урамы, 5;
3) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урамы, 14;
шулай ук «Волжские зори» («Идел таннары») газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, «Идел таннары» район газетасының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

“Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге”
башлыгы, “Татарстан
Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге”
Советы рәисе И.Х.Сәгдиев